**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2024 **Чирмешән авылы** **№190**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының маневрлы муниципаль торак фондына муниципаль торак урынны күчерү турында**

Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Торак кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге Федераль законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы «Торак урыннарын махсуслаштырылган торак фондына кертү кагыйдәләрен һәм махсуслаштырылган торак урыннарын наймлауның үрнәк шартнамәләрен раслау турында» гы карарына, Россия Федерациясенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 14 маендагы 292/пр номерлы боерыгына, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының маневрлы муниципаль торак фондының торак урыннарын формалаштыру һәм бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2024 елның 28 мартындагы 237 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының маневрлы муниципаль торак фондының торак урыннарын формалаштыру һәм бирү тәртибе турында нигезләмәгә яраклы рәвештә Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Чирмешән авылы, М.Титов ур., 15 йорт, 4 фатир адресы буенча урнашкан торак урынны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының маневрлы муниципаль торак фондына күчерергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе И.М.Җамалетдинов